РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**03.10.2025** **Чистай шәһәре** **№ 2/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Җир салымын гамәлгә кертү, ставкаларны, түләү тәртибен билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 9/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Җир салымын кертү, ставкаларны билгеләү, түләү тәртибен гамәлгә кертү турында» 2016 елның 10 декабрендәге 9/1 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2017 елның 7 августындагы 16/3 номерлы, 2018елның 27 июнендәге 26/3 номерлы, 2018 елның 23 ноябрендәге 29/2 номерлы, 2019 елның 7 октябрендәге 39/3 номерлы, 2019 елның 23 октябрендәге 40/2 номерлы, 2021 елның 28 апрелендәге 7/3 номерлы, 2021 елның 22 октябрендәге 10/3 номерлы, 2023 елның 19 октябрендәге 24/2 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасының өченче абзацында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм аларның кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3 пунктның тугызынчы абзацында күрсәтелгән кадастр бәясенең әлеге абзацында күрсәтелгән 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов